**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ**

# КАРАР

01.03.2016 Яр Чаллы № 509

2016 елда Тукай муниципаль районы территориясендә язгы ташу чорында биналарның, күперләрнең, автомобиль юлларының, гидротехник корылмаларның, торак фондның, башка матди кыйммәтләрнең һәм кешеләрнең тормышын саклау турында

Тукай муниципаль районында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү 2016 елгы язгы ташу чорында халыкны, хуҗалык һәм торак объектларны, гидротехник корылмаларны, юлларны һәм күперләрне саклау: максатында

**КАРАР БИРӘМ:**

1. «Тукай муниципаль районы территориясендә 2016 елда язгы ташу күренешләренә бәйле булган гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча чаралар планы»н кушымта нигезендә расларга.

2. Тәкъдим итәргә:

а) Хуҗалыклар, предприятиеләр, оешмалар һәм торак-коммуналь хуҗалык учреждениеләре җитәкчеләренә, авыл җирлекләре башлыкларына:

- 2016 елның 20 мартына кадәр Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Гражданнар оборонасы өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру бүлегенең әйдәп баручы консультантына (Тукай муниципаль районы буенча) «Ташу» планнарын тапшырырга;

- язгы ташуга каршы чаралар үткәрү чорында мәсьәләләрне оператив хәл итү өчен җаваплы хезмәткәрләр арасыннан тәүлек әйләнәсе кизү торулар оештырырга;

- объектлар, биналар һәм корылмалар, хуҗалык эчендәге автомобиль юлларында су үткәрү торбалары һәм күперләрне кардан һәм боздан чистарту эшләрен оештырырга;

- су чыганакларының һәм сулыкларның пычрануын кисәтү максатында су алу корылмалары, минераль ашламалар саклау урыннары территорияләрен санитар чистартуны оештырырга;

- подвал биналарыннан һәм кар сулары җыелган урыннардан су суырту өчен булган чараларны әзерләргә, җитмәгәннәрен сатып алырга;

б) «Татавтодор» ААҖ Яр Чаллы филиалына:

- язгы ташу чорында район автоюлларында өзлексез хәрәкәтне тәэмин итү буенча чаралар күрергә;

- су үткәрү торбаларын, күперләрне кардан һәм боздан чистарту эшләрен

оештырырга.

в) Тукай районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә:

- район хуҗалыкларында язгы ташу башланганчы тупас һәм сусыл азык запасы булдыру буенча эшне оештырырга;

- эшләүче персоналны эвакуацияләү, су баса торган территорияләрдән терлекләр һәм матди кыйммәтләрне чыгару буенча чаралар билгеләргә;

г) Россия Эчке эшләр министрлыгының Тукай районы буенча бүлегенә:

- язгы ташу чорында автомобиль юлларының аеруча куркыныч участокларында ЮХИДИ хезмәткәрләре көче белән патрульлек итүне көчәйтү планын эшләргә;

- су басу куркынычы белән бәйле рәвештә кешеләрне вакытлыча эвакуацияләү мөмкин булган торак пунктларда гражданнарның мөлкәтен саклау чараларын һәм матди кыйммәтләрне саклау объектларын билгеләргә;

д) ТР буенча Яр Чаллы шәһәрендә, Актаныш районында Роспотребнадзор территориаль бүлегенә:

- торак пунктларның, терлекчелек комплексларының һәм су белән тәэмин итү чыганакларының территорияләре торышына санитар-эпидемиологик контроль оештырырга.

3. Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Гражданнар оборонасы өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру бүлегенең әйдәүче консультантына (Тукай муниципаль районы буенча)тәкъдим итәргә:

- район территориясендә язгы ташу торышы турында халыкка мәгълүмат җиткерүне оештырырга;

-район хуҗалыкларының язгы ташуга каршы комиссияләре эшчәнлеген координацияләргә.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе Р.В. Асылгәрәев